ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

_07.11.2025 № _812_____

**Товарлар җитештерүгә (сатуга), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны яисә алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алучыларны сайлап алу уздыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантларны алучыларны сайлап алуны уздыруны җайлый торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге №1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 октябрендәге 2272 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Товарлар җитештерүгә (сатуга), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны яисә алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында субсидияләр алучыларны - юридик затларны (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларны, физик затларны - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләрне сайлап алуны уздырырга.

2. Сайлап алуда катнашу өчен гаризалар кабул итү срогын 2025 елның 10 ноябреннән 2025 елның 18 ноябренә кадәр билгеләргә.

3. Субсидия алу турында гаризалар Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл ст. пос., Кооператив ур., 5, икътисад бүлеге (дүшәмбедән җомгага кадәр 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр).

4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokya-gora/tatarstan/ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә (икътисад буенча).

Җитәкче вазыйфаларын

Башкаручы М.Р. Булгаков